Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение «Средняя общеобразовательная школа №167 с углубленным изучением отдельных предметов» Советского района г. Казани

Образовательный центр «Магариф»

**Исследовательская работа**

# ПАТРИОТЛЫЛЫК ХИСЛӘРЕН ТӘРБИЯЛӘҮ ЧАРАСЫ БУЛАРАК РЕЗЕДА ВӘЛИЕВА ИҖАТЫ

**КАЗАНЬ – 2019**

ЭЧТӘЛЕК

КЕРЕШ..........................................................................................3-4

**БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК.**

Патриотик рух тәрбиясе чарасы буларак шигырьләр һәм

җырлар.....................................................................................................5-9

**ИКЕНЧЕ БҮЛЕК.**

Патриотик рух тәрбиясе чарасы буларак әкиятләр...............................10-12

ЙОМГАК...................................................................................................13

ФАЙДАЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ...........................................................14

# КЕРЕШ

**Теманың актуальлеге**. Резеда Тәфкалун кызы Вәлиева XX – XXI гасыр башы татар балалар әдәбиятын йөгерек укыла, тиз ятлана, шул ук вакытта тирән мәгънәгә ия булган шигырьләре, яхшыны яманнан аерырга өйрәткән әкиятләр, нәниләр тәрбиясендә terәк булган җырлы-биюле уеннар, сценарийлар белән баетуга зур өлеш кертә. Моннан кала, Резеда Вәлиева эшчәнлегенең бер тармагын шигъри тәрҗемәләр тәшкил итә. Кайсы гына жанрда иҗат итмәсен, Резеда Вәлиева балаларга "әсәрләрне сез яратырсыз, алар сезгә чын Кеше булып үсәргә ярдәм итәр дип ышанам" дигән теләк-өмет белдерә [Вәлиева, 2000: 4]. Әдибә атаган Чын кешенең иң асыл сыйфатларының берсен ватанпәрвәрлек, патриотлылык тәшкил итә, чөнки кеше яшәеше буенча үзен яшәгән илгә, үзен чолгап алган кешеләргә, туган як табигатенә, милләт үсешенә файда китерми икән, нинди генә акыллы, иҗади кеше булмасын, ул ихтирам яулап ала алмаячак, аның исеме тарих битләренә алтын хәрефләр белән язылып куелмаячак. Шул ук вакытта Резеда Вәлиева патриотлылыкны "мин туган ягымны яратам", "минем авылым (шәһәрем) шундый матур" дип, коры сүзләр тезмәсендә түгел, ә барыннан да бигрәк гамәлләрдә күрә. Аның өчен патриотлылык әхлак төшенчәсенең аерылгысыз бер компоненты буларак аңлашыла. Әйтергә кирәк, әдибә буларак та, педагог буларак та бу рәвешле фикерләүдә хаклык бар, чөнки "җәмгыятькә әхлаклы мөнәсәбәт тәрбияләү – димәк, гражданлык хисләре, париотизм, иҗтимагый һәм рухи активлык тәрбияләү. Кеше, димәк, үзенең шәхси тормышында, гаиләдә үзен билгеле бер җәмгыятьнең тулы хокуклы һәм җәмгыять алдындагы бурычларын тоя белгән гражданы итеп хис итәргә тиеш" [Хуҗиәхмәтов, 1998: 298]. Резеда Вәлиева шигырьләре, әкиятләре әхлакый-патриотик хисләр формалаштыру потенциалына ия. Әлеге фәнни эшебез кысаларында без игътибарыбызны шул мәсьәләгә юнәлтәчәкбез.

**Эзләнү эшебезнең темасы** – "Патриотлылык хисләрен тәрбияләү чарасы буларак Резеда Вәлиева иҗаты". Темабыздан чыгып, эзләнү эшебезнең

**максатын** билгеләдек. Моның өчен алдыбызга –әдибәнең иҗаты белән танышу, патриотизм белән сугарылган әсәрләрен өйрәнеп, туган илебезне яратуны,саклауны, киләчәктә әхлаклы, зыялы шәхесләр булып үсүне, максат итеп куйдык.

Максаттан чыгып, эзләнү эшебезне башкарганда алдыбызга түбәндәге **бурычларны** куйдык:

-әдәбинең тормыш юлын өйрәнү;

- Патриотик рух тәрбиясе чарасы буларак шигырьләр һәм
  җырлары белән танышу;

- тормышчан әкиятләрен уку, анализлау;

- Резеда Вәлиева эшчәнлегенең бер төре тәрҗемә әсәрләрен уку

**Тикшерү объекты –** Резеда Вәлиеваның иҗаты, патриотизм белән сугарылган әсәрләре.

Фәнни эшебезнең **структурасы** керештән, ике бүлектән, йомгактан һәм файдаланылган әдәбият исемлегеннән тора.

## Патриотик рух тәрбиясе чарасы буларак шигырьләр һәм җырлар

Фәнни эшнең әлеге бүлекчәсендә без әдибәнең патриотик рух тәрбиясе чарасы буларак бәяләнә алган шигырьләрен тематик төркемнәрен аеруны максат итеп куябыз һәм түбәндәге нәтиҗәләргә ирешәбез.

1) *туган якның матурлыгына дан җырлаган, аның газизлеген ассызыклаган әсәрләр*. Әлеге төркемгә “Тургай”, “Газиз туган җир генә”, “Табигать баласына” кебек әсәрләре керә. “Тургай” шигыренең лирик герое – тургай җырын ишетеп сокланырга, шул җырда туган якка мәдхия яңгырашын сиземләргә сәләтле ватанпәрвәр зат. “Газиз туган җир генә” шигырендә сандугач образы гүзәл табигатьле туган як тасвирын тудыру чарасы буларак кулланыла:

*Сайра, сайра, сандугачкай,*
*Кунып сөйгән талыңа.*
*Туган якның тын җилләре*
*Тылсым өрсен җаныңа* [Вәлиева, 2000: 6].

2) *туган тел турындагы шигырьләр төркеменә* “И, газиз туган телем”, “Туган тел”, “Иң зур мирас” кебек әсәрләрен кертеп тикшердек. Телнең кадерен белергә өйрәткән әсәрләрдә туган тел яңгырашы нәфис метафоралар белән чагыштырылып, телгә карата соклану, мәхәббәт уята. Мәсәлән, “Туган тел” шигырендә туган телдә чишмәләр чыңы, йөрәк сагышы, әнинең бишек җыры аһәңнәре сакланганы турында әйтелә. “И, газиз туган телем” шигырендә телебезнең катлаулы сынауларга дучар иттерелеп тә, имин килеш саклануына соклану белдерелә:

*Канлы көрәш утларында*
*корычланган тел бит син,*
*Билен бирмәс, үлем белмәс*
*Батырларга тиң бит син* [Вәлиева 2003: 348].

3) *батыр татар уллары, тугрылыклы кызларына дан җырлаган әсәрләрдән* “Илгә кайтты Исхакый”, “Муса Җәлил – халкым улы”, “Ил яклар

ир булып үсегез”, “Безнең язлар мәңге Тукайлы” шигырьләре, “Шагыйрь гомере” поэмасы керә. Әдибә атаклы шәхесләрнең язмышын мисал итеп китереп кенә калмый, турыдан-туры нәсихәт бирүгә дә күчә:

*Күп еллар үтсә дә,*

*Сулмасын йөрәктә хисегез.*

*Мусалар шикелле,*

*Алишлар шикелле*

*Ил яклар ир булып үсегез!* [Вәлиева, 2000: 73].

4) *татар тарихына игътибар юнәлткән әсәрләрдән* “Кайда соң син, Болгар илем?”, “Изгеләр тавы” кебек шигырьләрен атарга мөмкин. Әдибә күп кенә татар балаларын борчыган сорауны бирә: тарихыбызның шөһрәтле сәхифәләре мәңгегә югалдымы, әллә кире кайтырмы эле? Шуларны уйлап, әдибә теләк-өметләрен дә белдерә:

*Шөһрәт алган Болгар иле,*

*Кайтсын иде безгә кире.*

*Сылу кызлар, кыю уллар,*

*Сезне бирер нинди юллар*? [Вәлиева, 2000: 40].

5) *Бөек Ватан сугышында Ватанны яклап сугышучы әби-бабаларыбыз хөрмәтенә язылган әсәрләр*. Болардан “Тугызынчы май”, “Башың и аңа”, “Җиңү көнендә”, “Юл куймагыз канлы дәһшәткә”, “Ыңгырашып куйды Җир-ана” әсәрләрен атарга мөмкин. Бу шигырьләр купшылык белән, пафос белән язылмаган, ә бәлки “вакыйгаларның хәтәр агышы” турында кисәтәләр [Вәлиева, 2000: 16], Җиңү көненең “авыр бәйрәм” булуын искә төшерәләр [Вәлиева, 2000: 41]. Шунысы игътибарга лаек – лирик герой Җиңү көнендә тантаналы бәйрәм кәефе кичерми, ә бәлки яраткан әбисенең сугыш кырында югалткан улы кайгсын җиңеләйтү юлларын эзли:

*Мин чәчәкләр җыям аңа,*

*Бүлмәсенә ямьнәр тулсын.*

*Җиңү белән бергә илгә*

*Улы кайткан кебек булсын* [Вәлиева, 2000: 41].

Мондый әсәрләр хәзерге балалар, үсмер һәм яшьләр өчен аеруча әһәмиятле. Еллар агышы сугыш китергән авырлык, кытлык, кара кайгының шаһитларын гүргә кертә барган саен, шул авырлыклар онытылып, җиңү романтикасы гына саклана. Фронттагы авырлыкны, тылдагы аяныч шартлардагы өзлексез эшне үз җилкәсендә татымаган яшьләр җиңүне бик җиңел бирелгән, дип уйлый башлыйлар, хәтта машиналарга “тагын кабатлый алабыз!” (можем повторить) (Европа илләре белән сугышып, аларны җиңү мәгънәсендә)  дигән язулар ябыштыру  кебек җилбәзәк гамәлләр шул хакта сөйли.

6) *илнең яшь гражданнарында хезмәт сөючәнлек, тырышлык, намуслык кебек сыйфатлар тәрбияләүгә юнәлтелгән шигырьләр*. Мондыйлар рәтендә “Күлмәк тектем”, “Сүз тыңлаучан булыгыз”, “Без игенчеләр булдык”, “Масайган Наил” кебек әсәрләрне карарга мөмкин. Әдибә өчен кешедәге иң мөһим сыйфатлар – тырышлык, тыйнаклык, әти-әни кадерен белү, табигатькә сак карау. Мондый әсәрләрнең лирик герое, урманга керсә, җиләкләрне аваз итәргә рөхсәт сорый; ата-бабалары кебек Акбүз атта чаба; болындагы чәчәкләрне күрсә дә, өзеп алмый; ташбакалар белән сөйләшә; аландагы иң эре җиләкне әнисенә алып кайта. Әмма әдибә кире күренешләрне дә сурәтләүдән тайчынмый. Менә бер шигыренең герое – Барый исемле малай телевизор карый-карый классында икенче елга калган; Наил исемле малай, масаеп йөри торгач, барлык дусларыннан колак каккан; көяз кызый Гөлгенә көзге каршында матурлана-матурлана “нәстәяшни шамакай”га әверелә. Гомумән, шагыйрә әсәрләрендә тышкы матурлыкның әһәмияте зур түгел, дигән фикер алга сөрелә. Мәсәлән, “Масайган Наил” әсәренең герое баһадирларча күренә:

*Соклана иде аңа күршеләр:*

*Зур кара күзле,*

*Түгәрәк йөзле,*

*Таза беләкле*

*Һәм киң күкрәкле.*

*Гел аны мактап*

*Сөйлиләр иде.*

*“Баһадир булыр*

*Бу”, – диләр иде* [Вәлиева, 2000: 4].

Табигать малайга карата әнә шундый юмартлык күрсәтсә дә, малай аның кадерен белми, масаеп, кешеләрнең күңелен үзеннән кайтара.

Резеда Вәлиева җырлар авторы буларак та билгеле. Бу өлкәдә, төрле композиторлар белән берлектә, ул аеруча соңгы елларда актив иҗат итә. “Җыр – татар сәнгатенең иң популяр һәм аеруча тиз үсә-үзгәрә торган жанрларыннан берсе буларак, татар менталитетының чагылыш гына түгел, бәлки мәдәниятнең гомумторышы, халыкның рухи тормышы күрсәткече дә” [Миңнуллин, 2003: 3], – дип яза хаклы рәвештә К.Миңнуллин. Әмма, шунысы характерлы: татар балалары өчен иҗат ителгән, балалар тормышын чагылдырган җырларны иҗат итүчеләр юк диярлек. Бу бушлыкны тутыруда Резеда Вәлиева керткән өлеш әйтеп бетергесез зур. Аның җырлары бала психологиясен чагылдырып кына калмый, милли колорит белән дә баетылган. Татар кешесе өчен сәхнәдә саф татар телендә энҗеле калфак турында җырлаган кыз баланы тыңлау, караудан да ләззәтлерәк күренеш буламы икән? Әйе, һәр бала кебек үк, бу җыр героинясы да яңа бүләккә – әбисе тарафыннан бирелгән калфакка куана:

*Калфагымның матурлыгын*

*Һәммәсе дә күрсеннәр,*

*– Энҗе калфак кигән кыз ул –*

*Татар кызы, дисеннәр* [Вәлиева 2003: 617].

Икенче бер шигырендә (төгәлрәк әйткәндә, җырында, “Кәләпүшем, кәләпүш” шигыренә Л.Батыр-Болгари көй иҗат итә) лирик герой бабасы тарафыннан бүләк ителгән кәләпүш белән ихластан мактана, бүләк белән горурлана:

*Кәләпүшем, кәләпүш,*

*Энҗе-мәрҗәннәр чиккән!*

*Чиккән кәләпүш үземә*

*Бигрәк килешә икән* [Вәлиева 2000: 110].

Шушы юллардан аңлашылганча, җыр милли үзаң сыйфатын үстерүдә дә зур роль уйный.

Шагыйрә иҗат иткән җырларда бәйрәм темасы (“Әниләр бәйрәме”, “Бәйрәм җыры”), җәнлекләр (“Без үрдәкләр”, “Елак песи”), милли кием (“Кәләпүшем, кәләпүш”, “Казански күн итек”, “Энҗе-мәрҗән калфагым”), туган җир (“Туган җирем”, “Авылым киче”), табигать матурлыгы, аңа мөрәҗәгать (“Яңгыр, яу”, “Уяталар”, “Исәнме, чыршыкай!”, “Яз җитте”, “Салават күпере”), гаилә (“Әткәем”, “Рәхмәт, әнкәй, сиңа”), илгә хезмәт итү теләге темалары (“Җырчы буласым килә”) урын ала.

**Патриотик рух тәрбиясе чарасы буларак экиятләр**

Резеда Вәлиева иҗатының мөһим юнәлешен әдәби экиятләр язу тәшкил итә. Аларда да шигъри иҗаттагы тема, идеяләр үзенчәлекле яңгыраш ала. “Серле үлән” экиятенә игътибар итик. Ул маҗаралы вакыйгалары, тылсымлы предметларының кодрәтле көче белән игътибарны җәлеп итми. Әкияттә сихри көчкә ия булган бердәнбер әйбер – Ананың сугышка китәр алдыннан улына биргән мәтрүшкә. Егет иң авыр мизгелдә, авыр яраланып, фашистларга каршы берүзе калган мәлдә шушы мәтрүшкәне иснәп хәл ала: “сулавы булган, татлы мәтрүшкә исеннән үзенең газиз туган яклары, аның иксез-чиксез киң кырлары, чәчәкле болыннары, сөекле әнкәсе күз алдына килгән. Ә алар күз алдына килүгә, ни хикмәттер, күкрәгенә дулкын-дулкын булып көч-гайрәт иңгән. Беләкләренә хәл кергән, күзләре үткенләнеп, нурланып яуган. Һәм егет автоматын үрелеп алган да якынлашып беткән дошман өеренә ут яудырырга тотынган” [Вәлиева, 2000: 46]. Резеда Вәлиеваның шигъри иҗатында игенчелек хезмәтенә дан җырлаган әсәрләр урын алса, экиятләрендә ипигә хөрмәт белән карау идеясе “Тылсымлы ризык”та урын ала. Әдибә фикере Карт авызыннан әйттерелә: “синең сабый улыңны ипекәй тикше ипекәйдән өстен куйганнар. Алар аңа гел ширбәт тә, бал-май да, җиләк-җимеш тә, алма да хөрмә генә биреп торганнар. Ә ипекәй, үзең дә белә торгансыңдыр дип ышанам, ипекәй у адәм баласы өчен иң кирәкле, иң зарур вә иң кыйммәтле ризыктыр! Ниләр генә ашаса да, нинди генә шифалы сулар эчсә дә, ипекәйдән башка адәм баласы менә шулай кибә, сүнә, сүрелә ул” [Вәлиева, 2000: 43].

Әдибә иҗат иткән экиятләрнең бер төркеме әхлакый тәрбия бирүгә юнәлдерелгәннәр. Аларда ярдәмчеллек, тыйнаклык мактала, ә явыз, гайбәт сөйләшүче, көнче геройлар тәнкыйть утына алыналар. Бу экиятләр традицион халык әкиятләреннән еш кына аерылып та торалар. Резеда Вәлиева экиятләренә хас үзенчәлекләрнең берсе – нәтиҗәне, әкияттә алырга тиешле сабак, нәсыйхәтне баланың үзеннән әйттерү. Мәсәлән, “Ак песи” экиятен алыйк. Ак песи белән соры песи зәңгәр капкалы йортта яшиләр икән,

бер көнне болар янына көчек килгән. Акыллы соры песи көчеккә сөт эчерткән, үссүзле ак песи тырнакларын очлайтып, янап торган. Көчекнең хуҗасы шәһәргә бәйгегә киткән икән, ә олылар аңа ашарга салырга оныталар. Әмма вакыт узу белән, ситуация көзгедәгедәй кабатлана. Бу юлы, хуҗа әбиләре авырып китү сәбәпле, ак песи белән соры песи ачтан интегәләр. Шунда инде танышларына көчек ярдәмгә килә. Тик ак песи генә көчекнең күзенә карарга ояла. Әкият әдибәнең нәни дусларына сорау куюы белән тәмамлана: “Нәрсәдән шулай ояла икән ул?” [Вәлиева 2006: 23]. “Күбәләк һәм кырмыска” экиятендә күбәләкнең кырмыска алдында бал кортын хурлавы сурәтләнә. Әмма кырмыска аңа кырыс һәм гадел җавап та бирә, бал җыю җиңел эш икән, үзенә шул эшне башкарып чыгарга тәкъдим итә. “Күбәләкнең нишләптер моңа бик нык хәтере калды, күңеле тулды. Ул шунда ук Кырмыска оясы яныннан очып китте һәм шул көннән алып Кырмыска белән исәнләшмәс булды. Нигә икән? Син ничек уйлыйсың?” дигән сорау белән тәмамлый экиятне Резеда Вәлиева [Вәлиева 2006: 22].

Резеда Вәлиева экиятләре тормышчанлык белән аерылып тора. Бу – сурәтләү объектларында да, тасвирланган вакыйгаларда да, хәтта әсәрләрнең тәмамлану рәвешендә дә чагылыш таба. Мәгълүм булганча, халык экиятләре явызлыкның тар-мар ителүе, бәхетле финал белән тәмамлана. Резеда Вәлиева экиятләрендә явызлык җиңелсә дә, аның эшәкелеге эзсез узмый, башкаларга үзенең һәлакәтеннән соң да авырлык китереп тора. Мәсәлән, “Мактанчык Бака” экиятендә башкаларны эшәке теле белән рәнҗеткән Баканы ләкләк ашый, әмма шуннан соң аның атна буена эче авырта. “Апа һәм сеңел” экиятендә ямьсез сеңел чибәр апасын бар йөрәге белән ярата, аның һәр теләгән үти, апасының исәнлеге – аның өчен иң зур бәхет. Чибәр апа исә сеңелнең тырышлыгы, мәхәббәтеннән иркен файдаланса да, аның ямьсезлеген ассызыклап мыскыл итә, хәтта үлемен дә тели. Әкият ахырында сеңел чибәр кызга әверелә, лачындай егет аңа ярәшергә тели, ялкау апа исә көнчелектән кара көя. Явызлык җәзасын алган кебек булса да, экиятнең финалы бәхетле дип әйтеп булмый, чөнки апасының мәңге көнче, ялкау

калачагын аңлаган, аны ямьсез кыяфәттә күргән сеңелнең кичерешләре гаять тирән, әрнүле була.

Резеда Вәлиева эшчәнлегенең бер төрен тәрҗемә әсәрләре тәшкил итә. Ул тәрҗемә иткән әсәрләр тема һәм жанр ягыннан әдибәнең үз иҗатына якын тора. Резеда Вәлиева күпсанлы шигырьләр, әкиятләрнең татарчага тәрҗемәсен эшли. Алар арасында А.Л.Бартоның “Безнең бәйрәм” (“Наш праздник”), С.В.Михалковның “Дустым белән икебез” (“Мы с приятелем вдвоем”), Н.М.Верзилинның “Робинзон эзләреннән” (“По следам Робинзона”), Н.В.Поповның “Андрейның яшьлеге” (“Юность Андрея”), Л.И.Смилянскийның “Сашко”, Л.Ф.Воронкованың “Дәү апа” (“Старшая сестра”), В.П.Тельпуговның “Ленин турында хикәяләр” (“Рассказы о Ленине”), Андри Тимеркаевның “Якшәмбе көн балыкта”, К.Чуковскийның “Бармалей”, америка язучысы һәм мультипликаторы Доктор Сьюзның “Патша Ташматча”, таҗик шагыйре М.Миршәкәрнең “Тугры дус” әкиятләрен атарга була. Бу тәрҗемәләр актуальлекләрен бүгенге көндә дә югалтмыйлар, балалар бакчалары тәрбиячеләре, ата-аналарга атап төзелгән хрестоматияләргә дә кертеләләр. Шунысы игътибарга лаек: Резеда Вәлиева тәрҗемә иткән әкиятләрне укып, балалар әхлакый тәрбия алып кына калмыйлар, ә төрле халык әкиятләре, язучыларның иҗатларындагы уртаклыкларны да күрергә өйрәнәләр. Мәсәлән, индонезия халык әкияте “Аю койрыгы” әкиятендә Юлбарыстан куркып калтырап торган Тиен хәйлә хисабына котыла: авызындагы чикләвекне ватып, “И тәмле дә соң Юлбарыс күзе”, дип кычкыра [Балачак аланы, 2011: 458]. Әлбәттә, Габдулла Тукайның “Кәҗә белән Сарык” әкияте белән яхшы таныш булган балалар ике әсәр арасындагы охшашлыкны күрә алалар. Икенче тәрҗемә әкият – “Төлке белән Аю” мари әкиятен укыганнан соң, балалар Төлкенең башка халык күзаллавында да хәйләкәр, ә аюның куркыныч, әмма беркатлы, бераз аңгырарак икәнен аңлый. Мондый ачышлар башка халыкларны, милләтләрне дә “үз” итеп кабул итергә булыша, милләтара дуслык тәрбиясенең бер чагылышы булып тора.

# ЙОМГАК

Резеда Вәлиеваның туган җиргә мәхәббәт, туган телне кадерләү, сугышка нәфрәт, каһарман татарлар белән горурлану мотивлары белән сугарылган, шулай ук тырышлык, батырлык, тугрылык кебек сыйфатларны мактаган шигырьләренең патриотик тәрбия бирүдә потенциалы шактый зур. Моннан кала, Резеда Вәлиева әкиятләр авторы буларак та билгеле. Аның әкиятләре күпсанлы маҗараларга, тылсымлы әйберләр, детальләр дөньясы, магик дөньяга ачкыч түгел. Резеда Вәлиева хайваннар турындагы әкиятләргә якын әсәрләр иҗат итә. Бу дөнья кечкенә балага яхшы таныш, шуңа күрә әсәрнең эчтәлегеннән чыга торган гыйбрәтле сабак та балага яхшы аңлашыла. Резеда Вәлиева әкиятләре традицион халык әкиятләреннән беркадәр аерылса да, тәрбияви потенциаллары шактый югары бәяләнергә хаклы. Әдибә әкиятнең әхлакый сабагын укучының үзеннән әйттерә; явызлыкның нәтиҗәсе яманлык булуын ассызыкллый, әмма явызлык җиңелгәннән соң да начар йогынтысы кала алу очраклары турында бәян итә. Әдибә иҗатында фольклорга барып тоташкан жанрларның тагын берсе – җыр да урын ала. Аның җырлары милли үзаң үстерүгә зур өлеш кертәләр. Резеда Вәлиева милләтләр дуслыгын үстерүгә дә үзеннән өлеш кертә. Аның әсәрләре аша тәрбияләнгән балалар туган илләренә дә тугрылыклы, намуслы, башка милләтләргә, илләргә карата да ихтирамлы булып үсәләр, дип ышанырга була.

# КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ


## Чыганаклар

1. Балачак аланы: балалар бакчалары тәрбиячеләре һәм әти-әниләр өчен хрестоматия. – Казан: РИЦ, 2011. – 560 б.
2. Вәлиева Р. Нәниләргә бүләк: мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен. – Казан: Раннур, 2000. – 14 б.
3. Вәлиева Р. Кояшлы яңгыр: сайланма әсәрләр. Шигырьләр, поэмалар, әкиятләр, табышмаклар, сценарийлар, җырлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 655 б.
4. Вәлиева Р. Ак песи: әкият тыңлыйбыз. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 24 б.

## Фәнни әдәбият

5. Миңнуллин К.М. Һәр чорның үз җыры. – Казан: Мәгариф, 2003. – 400 б.
6. Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Педагогика: педагогик уку йортлары, көллиятләр, гимназияләр, лицейлар өчен уку әсбабы. – Казан: “Матбугат йорты” нәшр., 1998. – 503 б.